# Нәрсә ул традицион татар исламы

(*Галим һәм мәгърифәтче Хөсәен Әмирханның тууына 200 ел*)

Күптән түгел "Ислам тудей" сайтында Рәзидә Сафиуллинаның бер фикерен укыган идем. "Татарстанга ислам куркынычы яныймы" дигән әңгәмәдәше биргән сорауга ул Татарстанга ислам куркынычы түгел, исламны дөрес аңламау куркынчы яный дип җавап биргән иде. Чыннан да җитмеш ел буена дәһрилек белән сугарылган халык егерме ел эчендә чын мөселман булып китте. Һәр тарафта мәчет, һәрберендә мәдрәсә, минбәрдә имам, көрсидә ректор, табында абыстай. Үзара талашып яткан мөфтиләр дә җитәрлек. Шатланырга гына иде. Әмма иртәрәк әле. Һәрбересе үзен генә хак, башкаларны нәхак саный. Бу төрле ыгы-зыгыга, хәтта фаҗигаләргә китерә. Халык моны күреп мәчеттән ераклаша Бер олуг мөфтиебез әйтмешли, татарның ике проценты гына мәчеткә йөри. Ул да җомга көннәрендә генә. А калган туксан сигез проценты кая йөри? Моны бер Алла белә. Ярар, дөрес юлда йөрсәләр. Әмма өммәсез ислам, мәхәлләсез мөселман булмый. Патша вакытында бер өммә булып, мәхәлләләр корып тыныч кына яшәп яткан халык ник бу дәрәҗәгә төште соң? Нигә бер мөфти тотып торган татар өммәсен зәррә дәрәҗәсендә таркалган татарны йөз мөфти дә тотып тора алмый.

Бу аяныч хәләтнең төп сәбәбе большевизм фетнәсеннән соң буыннар бәйләнешенең, дини һәм милли традицийәләрнең өзелүендә дип уйлыйм. Бу бигрәк тә соңгы буыннарда ачык чагыла. Ата бабаларының яшәү рәвешләрен белмәгән, исламның илаһи асылын аңламаган, туган телен, милли гореф- гадәтләрен оныткан яшләр исламга килгән очракта да хакыйкәт эзләп чит-ят мәсхәбләргә, фиркаләргә мөрәҗәгать итәләр. Хәтта исламда милләт юк дигән коткы тараталар. Алар Рәсәйдә, Татарстанда ислам юк, булса да, ул хакимияткә хезмәт итә, ә менә ислам дөньясында ул саф килеш саклана дип уйлыйлар. Асылда мин монда әлләни явыз ният күрмим, әмма көфер дөньясының әлеге ялгыш инанулардан явызларча файдалану мөмкинлеген инкарь итә дә алмыйм. Әгәр ислам дөньясында барысы да дөрес-хак, чиста-саф, камил булса, үзара кан коюга, көфер дөньясына таянып бер-берләрен кяферләрне дә уздырып вәхшиләрчә юк итүгә барырлар идеме? Әлбәттә, бу вакыйгалар, Америка публицисты Патрик Бьюкенен теле белән әйтсәк, көфер дөньясының ислам дөньясына каршы алып барган дүртенче бөтендөнья сугышының аяныч нәтиҗәсе. Ул үзенең "Мәгърибнең һәлакәте" дигән бәхәсле, әмма популяр китабында яһүдләр, мөсөселманнар, кара тәнлеләр һәм башка эмигрантлар үтеп керүе аркасында Американың һәм бөтен көнбатыш цивилизациясенең бетүгә баруын кисәтә. Моны ул көнбатыш дөньясына хас милли, нәсара дине традицияләренең бетүендә, садум гонаһына батуында күрә. Шуны ул өченче бөтендөнья сугышы дип аталган "салкын сугыштан" соң дүртенче бөтендөнья сугышы дип атый. Шушы күзлектән чыгып хәтта Америка президенты Бушны да гаепли. Әмма яһүдләр тырышлыгы белән бар гаеп мөселманнарга кайтып кала. Буш исә үзен аклау максатыннан бар нәфрәтен мөселманнарга юнәлтә. Без аларны (ягъни, мөселманнарны) бер-бересенең кулы белән юк итәчәкбез дип әйтә һәм шулай итә дә башлый. Садум гонаһына баткан Аурупа да шуны куәтли. Рәсәй дә ярдәм иткән булып шул ук максатка эшли. Ә беркатлы мөселман бәндәсе аларның мәкерле уеннарына ышанып үзен-үзе бетерә. Шушы юл белән никадәр Азия-Америка цивилизацияләре туздырылды. Никадәр халыклар коллыкка төшерелде. Инде чират исламга җитте. Безнең дә кайбер дин-ислам

пәрвәрләребез шуны аңламыйча сукырларча аларның туймас карыннарына эшли. Садум дөньясы "демократиясенә" таянып халкын да үз артларыннан ияртергә тырыша. Әмма үзебезнең дөрес юлыбызны таба алмасак, көфер фетнәсенә ияреп бер-беребезне ашап кына бетерәчәкбез. Ә шулай да бу үлем бождрасыннан чыгып буламы? Исламга каршы рәхимсез сугыш алып барган дәһшәтле көчкә каршы торырлык куәт бармы? Булса аннан ничек файдаланырга? Һәм ничек итеп?

Әлбәттә, бар. Беренче чиратта Алла куәте. Моңа ышанмаган кеше мөселман була алмый. Бу нәрсә дигән сүз? Әгәр без чын мәгънәсендә Алла кануннары белән яши башласак бернинди дә явыз көч тә безне җиңә алмас иде. Әмма без алай яшәмибез. Яшәгән булып кыланабыз гына, йә Алланы бөтенләй инкарь итәбез. Гомумән алганда дөньяви кануннарны илаһи кануннардан өстен куябыз.

Бу беренче. Икенче чиратта без үзебезнең тарихыбызга мөрәҗәгать итәргә тиешбез. Анда нәрсәнең дөрес, нәрсәнең ялгыш икәнен күрербез. 1552 йылда дәүләтсез калгач ике йөз ел буйына бәйсезлек өчен көрәшнең кайнар фазасын үттек. Әмма уңышка ирешә алмадык. Тагы да тирәнрәк коллыкка баттык. Сан буенча урыска тигез халык аннан 15 тапкырга кимеде. Яһүдләр дә 135 елда Римга каршы Бар-Кохба хәрәкәте җиңелгәч, дөнья буйлап таралды. Бу аларга Гайсә пәйгамбәрне үлемгә хөкем иткәннәре өчен җәза булды Әмма Китап иңдерелгән халыкка 1812 елдан соң кендек җирләренә кайтырга мөмкинлек бирде. Татар исә ханнарының үзара тәхет бүлешеп Алла биргән дәүләтләрен җимергәннәре өчен инде 460 елга сузылган коллыкка төште. Шулай да кайчандыр исламны кабул иткән халыкны Алла үз рәхмәтеннән бөтенләйгә ташламады. Әби патша фәрманын сәбәп итеп аны тулы икыйраздан коткарды. Бөтенрусия мөселманнары диния идарәсен оештырып, татарга мәхәлләләр системасына корылган милли үзбилгеләнү хокукын бирде. Бу хокук чикләнгән булса да, ул татарны 200 ел буена милләт буларак саклап килде. Әлеге хокукны 1850 елда император Николай I дә раслады. Бу дәвердә татар эчтәлеге белән илаһи, формасы белән милли булган шәригать кануннары белән йәшәде. Шул сәбәпле тәрәккый үсеш кичереп Русийәнең мәртәбәле өммәтенә әйләнде. Әмма дөньяви кануннарны илаһи кануннардан өстен куйып шундый ук гонаһка баткан халык-лар белән бергә яңадан Алла тарафыннан каты җәзага тартылды. Илне Алланы инкарь иткән большевизм чире биләп алды. Алланың хаклыгы бик тиз расланды. Мең йыл буйына ислам кануннары белән йәшәгән халык берничә йыл эчендә иманнан язды, мәчетләрен җимереп ташлады, мәдрәсләрен япты, имамнарын утка салды. Инде өстән рөхсәт килгәч, бар да динле булды. Берәүләр йомышчы руханиларга, икенчеләр "радикал" исламчыларга әйләнделәр һәм кяфер коткысы белән бер-бересенә пычрак ата, төрле җинайәт тага, фетнәгә тарта башладылар.

Динне тыйып өстән фәрман килсә болар нишләр? Бер-бересен пычратып, дәһрилеккә кайтырлармы? Әнә бүген үк инде рәсми идеологларыбыз, кайбер йомышчы имамнарыбыз шәригатьтән (чынлыкта, диннән) ваз кичәргә чакыра. Аларга җавап итеп "радикалларыбыз" гыйлем эстәү, илаһи дәгъват кылу, мәгърифәт нуры тарату урынына диндә көчләү юк дигәнне онытып арага фетнә сала.

Шуңа күрә без йомышчы руханиларны да, фетнәче радикалларны да кабул итә алмыйбыз. Чөнки боларда иман керделе-чыкты. Дин көчәйгәндә алар батыр, дин зәгыйфләнгәч качып ятыр. Шуңа күрә безнең бабаларыбыз йомышчы да, "радикал" да булмаганнар. Якты көндә илаһи дәгъват кылганнар, караңгы төндә мәгърифәт нурын таратканнар. Шушы юлдан тайпылмыйча иманнарын сакла-

ганнар. Хөсәйен хәзрәт Әмирхан да шушы юлның иң күренекле вәкиле. Мин үземне аның дәвамчысы итеп тоям. Җасадыбыз төрле булса да җаныбыз бер.

Минем сүземне аның сүзе, минем гамәлемне аның гамәле итеп кабул итсәгез бик рәхмәтле булыр идем. Әйдәгез бергә булыйк – нийәттә, сүздә, гамәлдә.

Безнең нийәтебез – җәһлийәттән илаһийәткә чыгу, сүзебез – Алла сүзе, гамәлебез – пәйгамбәрләр гамәле. Бу юлда олуг имамнарыбыз, галимнәребез, фикер ийәләребез күп көч куйганнар. Дан-шөһрәт артыннан куылмаганнар, күбесе җәбер-золымга дучар ителгәннәр. Әммә берсе дә иманын сатмаган, йомышчы, “радикал” булмаган. Исламнан дөньяви сәйәсәт ясап фетнә чыгарып йөремегән.

Исламда милләт юк дип, мәктәбеннән, теленнән, исеменнән ваз кичмәгән.

Без аларны онытырга, пычратырга, кимсетергә тийеш түгелбез. Киресенчә, аларның хезмәтләрен барлап, өйрәнеп, заманча эшкәртеп халыкка кайтарырга, мәгариф системасына кертәргә, йәшәү рәвеше итәргә тийешбез. Моны безгә гарәп тә, төрек тә, урыс та, йәһүд тә эшләп бирмәйәчәк, дәүләт тә моңа битараф. Элек тә шулай булган, булачак та. Милләтне бары тик зыялылары гына коткара ала. Акчасыз, малсыз, исем-дәрәҗәсез. Миллионер, миллиардер игәнәчеләрдән дә әллә-ни көтәсе юк. Алар хакимийәт хупламаган бер эшне дә эшли алмыйлар. Гафу итсәгез шуны да әйтим инде. Без хөкүмәттән зур-зур исем-дәрәҗәләр алган күпчелек галимнәргә дә таяна алмыйбыз. Эзоп телендә диссертацияләр өчен генә язган хезмәтләре бер татар дәреслеге язарга да ярамагач, аларның татарлыгыннан ни файда? Җитмәсә алар шушы исем-дәрәҗәләренә таянып җәмгыйәви тормышның җаваплы урыннарында утыралар һәм татарның тәррәкый үсешенә киртә булып торалар. Милләтебез өчен эшләүче Марсил Әхмәтҗан, Җәүдәт Сөләйман, Тәлгать Галиулла, Хатыйп Миңлегол, Тәэминә Биктимер, Фоат Галимулла, Фирдәвес Гарипова кебек галимнәребезгә бу кагылмый, әлбәттә.

Ә иң ышанычлысы, безнең үз фән һәм мәгариф системасында калыпланган Утыз Имәни, Габделнасыйр Курсави, Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэтдин Фәхретдин, Муса Биги, Рәшит Ибраһимов, Хөсәйен Әмирхан кебек үз осталарыбыз, үз остазларыбыз, үз галимнәребез, үз гыйлем ийәләребез булырга тийеш. Әлбәттә, әле озак вакыт безгә чит-ят мохиттә гыйлем алырга мәҗбүр булган, әммә татар мохитенә хезмәт иткән бакалавр, магистр, доктор, профессор, академикларга да таянырга туры киләчәк. Нинди генә милләттән чыккан булсалар да.

Шушы гакыйдәдән чыгып мин үземнең татар милли мәгариф системасын төзедем, нәзари яктан да, гамәли яктан да. Әммә туксанынчы йылларда ул берникадәр дәрәҗәдә кулланылышка керсә дә, татар зыялылары тарафыннан әлегә кабул ителми. Чөнки бүгенге зыялыларыбыз рухына ят мохиттә формалашкан.

Шуның өчен безгә, беренче чиратта, виртуаль формада булса да үзебезнең МИЛЛИ ӨЛГЕБЕЗНЕ булдырырга кирәк. Мин аны үткән җыйында тәкъдим иткән идем инде. Әммә элегә туксанынчы йыллардагы шикелле зыялыларны туплый алмыйм. Шуңа күрә сезне барыгызны да конкрет хезмәттәшлеккә чакырам.

Безне татар-мөселман милләте буларак юк итүнең схемасы бик гади. Башта дөнҗяви хакимият дин дәүләттән аерылган дигән сылтау белән безне шәригатҗтән, мәхәлләбездән, гаилә институтыбыздан аера, аннан йомшчы руханиларыбыз исламда милләт юк дип мәктәбебезне, телебезне, имлабызны бетерә. Моны кабул итә алмаган “радикалларыбыз” көфер коткысына бирелеп безне фетнәгә кертә.

Нәтиҗәдә бөтен авырлык традиөион татар исламы тарафдарларына төшә. чөнки болар барысы да илаһи мәгүрифәтчелек юлын бергәләп инкарҗ итә.

Инде Резедә әйткән фикергә ачыклык кертү өчен кайбер терминнарга аңлатмалар бирик. Ягъни исламны ничек аңларга кирәклегенә ачыклык кертик.

ИЛАҺИ (ПРОРОЧЕСКИЙ) ИСЛАМ шәригать, ягъни Алла кануннары буйынча йәшәү рәвеше. Табигать кануннары да, дөньяви кануннар да алардан өстен була алмый. Шуңа күрә хәтта патша заманында да татар шәригать кануннары белән йәшәгән. Әмма шәригать кануннары көчләп тагылмый, аларны үтәү кешенең үз ирегенә куйыла. Илаһи дәүләт исә аның сагында гына тора. Кызганыч ки, бүгенге дөньяви дәүләтләр шәригать кануннары белән йәшәүне инкарь итә. Үзләренә муафыйк күләмдә кайбер йолалаларны үтәүгә генә рөхсәт бирә.

КЛЕРИКАЛ ИСЛАМ. Рәсми яктан дөньяви дәүләттән айырылган, әмма асылда дөньяви кануннарны илаһи кануннардан өстен санаган дөньяви хакимиятнең рухи йомышчысы вазыйфасын башкаручы мөселман чиркәве системасы.

ЙОМЫШЧЫ РУХАНИЛАР. Дөньяви кануннарны илаһи кануннардан өстен куйып дөньяви хакимийәт рөхсәт иткән күләмдә (нигездә, йола рәвешендә) дини тормыш белән идарә итүче указлы дин әһелләре ийерархийәсе.

МОНАФИ ИСЛАМ Илаһи кыйммәтләр системасын дөньяви максатларда файдаланган һәм шуның белән илаһи исламга зарар салган дөньяви ислам. Мисал итеп коммунизм идейәсе көчәйеп киткәч шәхси максатлардан партийә сафларына үтеп кергән монафыйкларның җимергеч эшен күрсәтергә була. Илаһи йәһуди һәм илаһи насара диннәренең бозылуы да шушы монафыйклыктан килә.

РАДИКАЛ ИСЛАМ. Шәригать кануннарын дөньяви кауннардан өстен куйган, әмма диндә милләт юк дип традицион исламны инкарь иткән, шәригать кануннарын мәҗбүри рәвештә урнаштырырга тырышкан фетнәчел ислам.

*Искәрмә.* Әйтеп үткәнемчә, йомышчы руханилар, радикал исламчылар, дөньяви дәүләтнең шәригать кануннарын инкарь итүенең аяныч фаҗигасе. Чөнки иман калимәсен ихлас күңелдән кабул иткән кеше шәригать кануннары белән йәшәргә тели һәм аларны тыюны кабул итә алмый. Барлык фетнә дә шуннан килә. Моннан ислам дошманнары оста файдалана. Ислам битлеге астында күп төрле җинайәт кылына. Кызганыч ки, без моның сәбәпләренә каршы түгел, нәтиҗәләренә каршы көрәшәбез. Мине үземне дә дөнҗяви хакимият, йомышчы ислам тарафдарлары, илаһи мәгүрифәт юлын инкарҗ итеп, шуңа тартырга тырыша.

ТРАДИЦИОН ТАТАР ИСЛАМЫ. Исламның хәнәфи мәзһәбе таләпләренә нигезләнгән шәригать кануннарына таянып йәшәгән, татар мохитендә калыпланган, гасырлар сынавы үтеп буыннан буынга тапшырылып килгән, мәҗүсилек халәтеннән чыгарып татарны милләт булып формалаштырган илаһи ислам.

МӘГЪРИФӘТИ ИСЛАМ. Традицион татар исламына нигезләнгән, татар милли өлгесен булдырып татар-мөселман мәхәлләләре аркылы мәгрифәт юлы белән тыныч рәвештә тормышка ашырыла торган мөселманча йәшәү рәвеше.

Бүгенге көндә, чын мәгънәсендә, шәригать кануннары белән йәшәүче бер генә дәүләт тә, бер генә халык та, бер генә милләт тә юк дияргә була. Бу исә клерикал һәм илаһи ислам тарафдарларын каршылыкка этәрә. Илаһи гыйлем зәгыйфь булганда бу каршылык фаҗигагә әйләнә. Бу халәттән безне илаһи гыйлемгә нигезләнгән мәгърифәти ислам гына коткара ала. Шуңа күрә дә без халыкка илаһи мәгърифәт юлын тәкъдим итәбез. Ул үз эченә ТАТАРНЫҢ МИЛЛИ ӨЛГЕСЕН һәм КАНУНЫН ***ала һәм халык идәрәсе булган мәхәллә системасы аркылы тормышка ашырыла.*** Әмма әлегә бу юлны кабул итүчеләр саны бик аз.

*Татар кануны түбәндәге өлешләрдән тора:*

Иман: фитрый иман, кәлимәи шәһадәт, кәлимәи иман.
Илаһи китаплар (Коръән, Инҗил, Зәбүр, Тәүрат, Сөннә).
Дин-гыйбадәт.
Шәригать: илаһи хокук, иҗма, кыяс, фәтвә.
Гореф-гадәт, йола, милли традиөияләр.
Рәсүлләр, нәбиләр, мөршидләр, галимнәр.
Өммә, дин кардәшлеге, рухи җәмгыйәт.
Кан кардәшлеге: гаилә, ыруг, кавем-кабилә, милләт, дәүләт.
Гаилә институты: төзек никах, хәләл җефет, мөселман гаиләсе.
Ил-җир: мәхәллә, авыл-бистә, район-илчә, өлкә-төбәк, ил-ватан).
Дөньялык һәм ахирәт (фанилык һәм бакыйлык).
Фарыз-сөннә, савап-гонаһ, хәләл-хәрәм.
Ийәлек, милек, мирас (байлык, фәкыйрьлек, мескенлек).
Салым-ясак, зякәт-садака, хезмәт хакы, пенсийә, бүләк-ришвәт.
Гыйлем-белем, фәлсәфә-гакыйдә, фән-мәгариф, мәгърифәт-тәрбия.
Идарә-хакимият (имам, хәлиф, патша, көтүче, көтү башы).
Ирек һәм коллык (хуҗа, түрә, кол).
Тел һәм имла,
Исем-атама, ономастика-топонимика.
Җиһад, фетнә һәм иҗтиһад..
Мәгълүмат һәм матбугат
Мәдәнийәт һәм сәнгать.
Җитештерү-куллану, сәүдә-табыш.
Яшәү мохите, рухи һәм җәсади сәламәтлек.
Исем-дәрәҗә, лицензия-сертификат, белешмә-таныклык.
Тарих-киләчәк, вакыт һәм заман.

Бу мәсьәләләр. әлбәттә, дәүләт структураларында төрле дәрәҗәдә эшләнгән. Әмма Шәригать кануннары һәм Татар кануны нигезендә түгел. Шуңа күрә алар, Ибн Халдун әйтмешли, халык җәмгыйәтенә түгел, айырым шәхесләр һәм социаль төркемнәр (асабийәләргә) файдасына эшли. Шуңа күрә халык һәм идарәче даирәләр арасында йыш кына конфликтлар туып тора. Бүгенге көндә илаһи кануннарга таянып йәшәүче бер генә ил бар. Ул да булса Израил. Анда конституция - Тәүрәт, дөньяви кануннар сисемасы – Талмуд. Әмма бу да формаль рәвештә.

Әлбәттә, меңәр йылга сузылган бу каршылыкны кыска гына вакыт эчендә бетереп булмый. Моның өчен зур түземлек, гыйльми дәгъват, илаһи мәгърифәт кирәк. Ирекне көч белән кертеп булмый. Моның өчен өсләрнең дә, асларның да хакыйкәтне аңлавы кирәк. Теләсә нәрсәне көчләп тагарга тырышу вакытлы уңышларга китерсә дә, берникадәр вакыттан тагы да зуррак бәла чыгаруы мөмкин.

Безгә кыска вакытлы коллар һәм түрәләр ротацийәсе түгел, бер имам, бер гакыйдә белән идарә ителә торган татар-мөселман өммәсе кирәк. Әгәр без кешеләрне сыйныфларга, мәзһәбләргә, традициалларга-радикалларга бүлеп эш итсәк, башыбыз бәладан чыкмаячак, милләт буларак инкыйраздан чыгу булмаячак.

Бүгенге шартларда шәригать кануннары дөньяви кануннардан никадәр айырылса да, илаһи мәгърифәт аркылы дөрес дәгъват кылсак, аларны якынайта алачакбыз. Чөнки һәр бәндә Алла биргән фитрый иман белән туа.